РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«23» сентябрь 2021 ел Олы Кайбыч ав. № 62

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 182 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021 елның 01 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 182 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау турында» (2020 елның 25 мартындагы 219 номерлы, 2020 елның 15 июнендәге 235 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 статьяның 9 пунктындагы дүртенче абзацта «, бюджет калдыклары белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

1.2. 15.11 статьясының 27 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кредит (заем, облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия, кредит килешүендә (заем килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне кредитор (заем бирүче) йөкләмәләрен бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән кредит (заем) акчаларының максатчан кулланылуын үз ягыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыру шарты белән бирелә.».

1.3. Әлеге карар, 2022 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның 1.1 пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы

А. И. Рәхмәтуллин